ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.06.2026 г. Заинск № 319

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 апрелендәге 226 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башлыгы Грантлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә «Мәгариф» өстенлекле милли проектын гамәлгә ашыру, иң яхшы педагогларны һәм укучыларны бүләкләү, педагогик бергәлекнең инновацион активлыгын стимуллаштыру максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 апрелендәге 226 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башлыгы Грантлары турында» карары белән расланган «Сәләтле укытучы – сәләтле укучы» район Башлыгы Гранты турында Нигезләмәгә (Башкарма комитетның 28.06.2022 № 311, 26.04.2024 № 264 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 1.1 пунктның беренче абзацында “гомуми белем бирү" сүзен «белем бирү» сүзенә алмаштырырга;
1.2. 1.4 пунктта "гомуми белем бирү" сүзен "белем бирү" сүзенә алмаштырырга;
1.3. 2.2 пунктның 1 абзацында "гомуми белем бирү" сүзен "белем бирү" сүзенә алмаштырырга.
2. Әлеге карарны “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында

урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Р.Н. Камаловага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Вәлиәхмәтова М.К.
9-90-19